Газета МБОУ «АСОШ №2»

# Пульс школы
# Мәктәп пульсы




№5
Март 2019 г.

## С приходом весны!

*Закончились метели.*
*Просох в лесу валежник.*
*К нам птицы прилетели!*
*В траве зацвёл подснежник!*
*Теперь светает раньше*
*И звонок день, как бубен.*
*Берёзки побелели*
*И нет на них зарубин.*
*А скоро сок по веткам*
*Помчит, их оживляя.*
*Весна пришла! Весна пришла!*
*Природа вновь живая!*

***Е. Арутюнова***



## Интересно знать!

- Рост Петра Первого составлял примерно 213 см.
- Глаз страуса больше его мозга.
- Деньги не сделаны из бумаги, они сделаны из хлопка.
- Библия — самая продаваемая книга в мире.
- Город Рим есть на каждом континенте.
- У мотылька нет желудка.
- Арахис используется при производстве динамита.

## Сказочные дворцы...



*Ученики нашей школы активно участвуют в экологических акциях, одним из которых является ежегодный конкурс скворечников **«Сказочный дворец».***
*Спешим огласить результаты:*
***1 место - Сабина Мингалиева, 2Г класс***
***2 место - 3Б класс***
***3 место - Реналь Боев, 5В***
*Поздравляем победителей и желаем дальнейших творческих успехов!*







## В этом выпуске:


| | |
|---|---|
| “Өч тиенлек” операга бишле куеп буламы? | 2 |
| «Татарин» дип үртәп йөрткәннәр... | 3 |
| Школьный профсоюз | 4 |
| Мәктәбебездә кичә | 5 |
| Республиканская конференция | 6 |

# “Өч тиенлек” операга бишле куеп буламы?

***Фән олимпиададалары күптән тәмамланды, ә аның онытылмас хатирәләре айлар дәверендә күңелне җылытачагына һич тә укенмим. Моның сәбәбе дә бик гади – бәйгегә бирелеп әзерләнгәнне күреп, укытучылар театрга билет бүләк иттеләр! Әле спектакле нинди диген – “Өч тиенлек опера”! Юк, юк, бәясен әйтәм дип уйлый күрмәгез, бу тамаша исеме генә!***

Василий Качалов исемендәге Казан дәүләт академия театры сәхнәсендә куелучы иң популяр спектакльләрнең берсе булып саналган “Трехгрошовая опера” турында сөйләвем... Хисләремне ничек кенә җиткерергә тырышсам да, бик аз булып тоелыр шикелле, чөнки әлеге күренешне тасвирлап бетерерлек сүзләр дөнья йөзендә әле юктыр да. Актерларның профессиональ уены, күз явын алырлык декорация, мавыктыргыч вакыйгалар дисеңме – барысы да зәвык белән югары дәрәҗәдә башкарылган.

Операның сәхнә язмышы нинди икән соң? Аның белән бергәләп танышырга тәкъдим итәм!

Немец драматургы Бертольт Брехт пьесасының тарихы ерак үткәннәргә барып тоташа. Әлеге спектакль Германия сәхнәләрендә аншлаглар җыя башлаганчы Лондон театрларында инглиз драматургы Джон Гей иҗат иткән “Ярлылар операсы” барлыкка килә. Ул инглиз илләренең югары катламнарында яшәүчеләрнең тормыш рәвешен һәм холкын, аларның явызлыгын мыскыл итүгә корылган була. Шушы спекакльдә тасвирланган вакыйгалар Бертольт Брехтның иҗатына нигез сала да инде.

“Ярлылар операсы”ннан аермалы буларак, Б.Брехт операсында төп урынны буржуаз җәмгыять сурәтләнү алып тора. Анда авторның замандашларына каршылыгы күзгә ташланмый, чөнки вакыйгаларның урыны, вакыты да төгәл әйтелми, бары тик шартлы рәвештә генә күрсәтелә.

Образлар системасына күз салсак, геройларның сыйфатлары бары тик бер кешегә генә хас булмаганлыгын билгеләп үтәргә кирәк. Персонажларның төп үзенчәлекләренең берсе – шул заманда яшәүчеләрнең барлык кимчелекләре һәм тискәре яклары исемнәрен чагылдырып торган экраннар, төрле төстәге утлар ярдәмендә яктыртылган сәхнә...

Һәм ниһаять 1928 елның 31 августында Берлин сәхнәсендә күптән көтелгән премьера! Гөрләп узган тамашаны тәнкыйтьчеләр дә үз итә, төрле газета-журналларда әлеге пьесага карата мәкаләләр барлыкка килә, халык аны сезонның иң сенсацион, иң горандиоз уңышы, дип йөртә башлый.

1957 нче елда Соломон Апт исемле данлыклы филолог һәм тәрҗемәче пьесаны рус телендә таныта. Нәкъ шушы тәрҗемә Качалов театрында куелучы спектакльгә нигез сала.



бер кешегә җыелуы. Тамашаны тагын да кызыграк, җанлырак итүдә моның әһәмияте шактый зур.

Табадан гына төшкән операны тамашачыга беренче тапкыр тәкъдим итәр алдыннан Брехт пьесаның немец композиторы Курт Вайль катнашында язылганлыгын әйтә, чөнки геройларның әйтәсе сүзләре еш кына музыка белән бергә барлыкка килгән. Кызыклы вакыйгаларның джаз жанрында язылган җырлар белән үрелеп баруы тамашачыда тагын да зуррак кызыксыну уята.

“Май ботканы бозмый,” – ди халык. Әлеге әйтем шушы спектакльгә карата да урынлы булыр иде: актерларның киемнәре, сәхнә бизәлеше, җанлы музыка, җыр

“Прованс” газетасында басылып чыккан мәкаләдә Казан артистлары турында менә нәрсә язалар: “Алар Б.Брехт текстын һәм К.Вайль музыкасын берләштерүчеләр, джаз, кабаре, халык җырларын җиренә җиткереп җырлаучылар. Алар халыкның игътибарын беренче минуттан ук оста яулап ала алалар... Үрнәк алырдай артистлар!”

Менә мин дә, тамашачы буларак, “Прованс”тагылар кебек “Өч тиенлек опера”га зур бишле билгесе куйдым!

**Рүзәл ШӘРИПОВ**,
9Б сыйныфы

# «Татарин» дип үртәп йөрткәннәр...

***Бүгенге көндә якты киләчәгебез турында тирәнтен кайгыручы кешеләр саны, әлбәттә, байтак, ә менә Фәрит Хәйрулла улы Мөхәммәтшин кебекләр бармак белән генә санарлыктыр.***



«Ялкын»ның «Лидерлар мәктәбе» проекты кысаларында уздырылган чираттагы очрашуда катнашучылар минем фикерне уртаклашмый калмас. Билгеле, тыгыз эш тәртибендә яшь буын вәкилләре белән очрашырга вакыт табу, җәмәгать эшлеклесенең аңлатып бетергесез эчкерсезлеге, күңел байлыгы һәм ихласлыгы гаҗәпләндерми кала алмый.

Әмма аның татар телен 40 яшендә генә өйрәнә башлавы игътибарымны аеруча җәлеп итте. Кыска вакыт эчендә туган тел белемен шулкадәр камил дәрәҗәгә җиткерү – үзе батырлык түгелме соң?! Балачакта «татарин» дип үртәп йөртүләре дә Фәрит аганың йөрәгендә тирән эз калдырган, ләкин кыюлык, үз-үзен җиңү теләге үз эшен эшли – республикабызга көчле рухлы, туган теленә тугры, туган иленең үсеше өчен утка да, суга да керергә әзер бөек шәхес бүләк итә!

# Өстеңдә кофта, ә аякларыңда - итек! Нишләргә?

***Күз алдыңа китер, син сәхнә артында. Кинәт алып баручы синең исемеңне әйтә. Син каушыйсың, чөнки әлеге чыгыш синең киләчәгеңне хәл итә. Куркуыңны җиңеп сәхнәгә таба атлыйсың... Тукта-а-а! Синең бит өстеңдә кофта, ә аякларыңда - итек! Нишләргә?***

Ә Зәринә Никитина бу кыен хәлдән чыгу юлын тиз тапкан! Ничек икәнен беләсең киләме? Әлеге мәкалә синең өчен!

Зәринә – Арчаның гаҗәеп матур, көчле тавышлы сандугачларының берседер, мөгаен. Аның район, республика, халыкара бәйгеләрдә яулаган җиңүләрен санап бетергесез. Шуларның берничәсен генә әйтим инде: Халыкара “Җырлы-моңлы балачак” телевизион конкурсында лауреат була. Республиканың Рөстәм Яхин исемендәге “Күңелемдә яз” һәм халыкара “Тере чишмә” конкурс-фестивальләрендә 2 дәрәҗәдәге лауреат!

**- Зәринә, җыр сәнгате белән күптәннән шөгыльләнәсеңме? Әлеге адымны ясарга сине нәрсә этәрде?**

- Мин инде балачактан ук җыр-моңга гышыйк кеше. Әни, минем гел җырлап йөргәнемне күреп, җыр мәктәбенә йөртә башлады. Баштарак бик ярата идем, тик соңыннан фортепианода уйнау дәресләре туйдыра башлады. Көннәрдән беркөнне ноталар дәфтәремне мәктәптә яшердем дә, өйгә кайтып: “Әни, урлаганнар! Җыр дәресе буенча барлык китапларымны урлаганнар! Хәзер вокалга йөри дә алмам инде...” – дидем. Әни барысын да аңлаган, күрәсең: ризалашты..

**- Синең кебек зур уңышка ирешер өчен нишләргә кирәк?**

- Беренчедән, үзең өстендә, хаталарың өстендә гел эшләргә кирәк. Чыгыш ясаган саен, мине видеога төшерергә кушам. Бары тик үзеңне - үзең күреп кенә, хаталарыңны төзәтергә мөмкинсең. Икенчедән, син һәрвакыт остазың белән бер дулкында булырга тиеш. Аны бер караштан аңлап, ул куйган таләпләргә яраша белергә кирәк. Өченчедән, үзеңә ышан, сәхнәдән курыкма! Бик тиздән бу курку үзеннән үзе юкка чыгачак. Әлеге гади кагыйдәләрне гел исеңдә тотсаң, уңыш синең кулыңан төшәргә дә теләмәс!

**P.S.** Теге кызык хәлнең ахыры турында сөйләргә онытып торам бит әле! Зәринә ул вакытта югалып калмаган. Янында торган бер белмәгән кызның туфлиларын салдырып аягына кигән дә, кофтасын идәнгә ташлап, сәхнәгә чыккан. “Калтырап торганымны жюри әгъзаләре сизмәгән ахрысы! Беренче урын биреп кайтардылар бит!” - дип шаярта үзе.

**Рүзәл ШӘРИПОВ**, 9Б сыйныфы

# Школьный профсоюз



***Профсоюз – это добровольное объединение людей той или иной профессиональной направленности, с общими интересами. Объединения такого типа существуют во всех организациях, а выбор вступать или нет в нее, остается за самим человеком.***

В такие союзы больше присоединяются люди с активной жизненной позицией, способные защищать как свои права и интересы, так и своих коллег. Но не многие знают чем же все-таки занимается профсоюз. С чем его «едят»? Какие вопросы обсуждаются? Чем они могут облегчить жизнь сотрудника? Стоит ли вообще в нее вступать?! Стоит лишь капнуть поглубже, но не уходя далеко, и ответы на эти вопросы исчезнут.

В каждом общеобразовательном учреждении есть такие профсоюзные комитеты, и конечно в нашей школе он также . С этими вопросом я решила обратиться к Файзуллиной Алсу Мустафовне – председателю школьного профсоюзного комитета

**- Алсу Мустафовна, сколько лет вы работаете в данном объединении?**

- Председателем профсоюза я работаю более 8 лет.

**- Каковы преимущества профсоюза?**

- Во-первых, он дает самоуверенность в себе, что очень важно в наши дни. В нужное время он помогает решать важные проблемы. Если ты входишь в это объединение, то ты чувствуешь себя защищенной.

**- Какие вопросы решаются в нашем школьном профсоюзе?**

- В нашей школе объединение профсоюза делает все согласовав с администрацией. Все важные вопросы как: охрана труда, составление расписаний, ремонт, разделение учителей, составление коллективных договоров и контроль над ее выполнением, материальная помощь нуждающимся, укрепление здоровья учителей, а также праздники: Новый год, 23 февраля, 8 марта… – все это делается вместе с ней.

**- Добровольно ли ваши коллеги вступают в нее?**

- Вступать в профсоюз не обязательно, но всё ведь ради благ самих же моих коллег, и они, понимая, добровольно идут на это. Даже в старости, когда придет время выхода на пенсию, все проблемы будут решаться именно профсоюзом, что намного облегчит их жизнь.

**- Затрагиваются ли такие темы как ОГЭ и ЕГЭ в профсоюзе, ведь с каждым годом они становятся все сложнее и сложнее?**

- Конечно, вопросы, связанные с экзаменами в профсоюзе рассматриваются. Все изменения, которые вносятся, нами изучаются, однако внесение изменений с нашей стороны невозможна, ведь даже министерство образования РТ не может вносить изменения. Изменения, вносимые в экзамен, решаются Министерством РФ.

**- Многие ученики хотят продлить перемену с 5 минут до 10. Как будет рассматриваться такое предложение?**

- Перемены в нашей школе 5 минут, лишь после 2-го и 5-го урока, а остальные перемены по 10 минут, и во время обеда все зависит от самих учеников. Если ученик быстро ест, то он успевает требуемой норме, но если же не успевает, данная перемена удлиняется, а остальные перемены сокращаются.

Длительность перемен сделано по нормам СанПиНа, и изменять ее не в нашей власти. Все делается ради улучшения жизни ребенка. Конечно можно было бы сделать перемены и по 15, и по 20 минут, но ребенок не проведет это время с пользой, он будет сидеть и играть в телефоне. А организм ребенка устает за весь день, и не будет воспринимать нужную информацию.

***Профсоюз –***
***это сила, а также:***

- ***профессионализм;***
- ***разумность;***
- ***ответственность;***
- ***самостоятельность;***
- ***солидарность;***
- ***организованность;***
- ***юридическая помощь;***
- ***законность.***

После разговора с председателем школьного профсоюзного комитета, мы действительно можем понять, что это нужный в современном мире орган, который помогает и решает многие жизненные вопросы.

**Ляйсан САФИНА,**
член клуба юных журналистов
«Тукай якташы»

# Величайшее богатство народа

***Язык – это целый мир, полный прелести, обаяния и волшебства. Он – живая память народа, его душа, его достояние. Язык - величайшее богатство народа.***




Самой большой ценностью, которой должен гордиться каждый народ, является родной язык. Ведь именно слова на родном языке слышит малыш сразу после рождения, впитывая вместе с молоком матери культуру, обычаи и традиции своего народа.

У каждого есть свой язык, своя национальность. У каждого он свой, особый. На этом языке разговаривали наши прабабушки и прадедушки. Свое первое слово мы сказали на своем родном языке.

Недавно во всем мире отметили Международный день родного языка. И в нашей школе в честь этого дня было проведено мероприятие, на котором были приглашены все учителя и ученики школы. Школьники могли показать свои умения и навыки.

По доброй традиции в этот день у нас у всех в одежде применяются элементы национальной одежды. Мы с удовольствием демонстрируем наши красивые тюбетейки, колпаки, фартуки, ичиги.

Наш праздник мы начали со стихов. Детям было предоставлено слово, что бы они могли показать себя, свои способности. Кроме татарского языка мы услышали стихи на русском, узбекском и на азербайджанских языках.

Также слово было предоставлено вокалистам нашей школы: Шафиковой Алине, Шайдуллиной Ляйсан, Шавалиевей Зиле и Зайнуллиной Алине.

Учащиеся начальных классов смогли показать свои навыки по танцам. Мы на этом вспомнили своих великих поэтов, писателей. Расширили знания и повысили свою мотивацию для того, что бы и дальше изучать родной язык. В конце мероприятия мы спели песню Габдуллы Тукая «Туган тел».

Никто не остался равнодушным и с удовольствием провел этот день.

**Адиля ГАЛИМЗЯНОВА,**
член клуба юных журналистов «Тукай якташы»

# Мәктәбебездә кичә

*Татарча да яхшы бел,*
*Русча да яхшы бел.*
*Икесе дә безнең өчен*
*Иң кирәкле татлы тел.*

Һәр кеше үзенең туган теленнән дә матуррак, якынрак тел юктыр ул. Мин дә үземнең туган телемне бик яратам. Дөньядагы барлык телләрдән дә матуррак яңгырашлы бит ул татар теле!

Күптән түгел мәктәбебездә “Без туган телебезне яратабыз” дигән кичә үткәрелде. Канатлы сүзләр әйтелде, матур җырлар җырладык, мәкаль – әйтемнәрне белүебез -не сынадык. Иң күңеллесе– ШТК ярышы булгандыр. “Тапкырлар” һәм “Зирәкләр” командалары үзара көч сынаштылар. Ярыш бик кызу барды, биремнәр дә җиңелдән булмады. Телгә багышланган кызыклы плакатлар чыгардык, башваткычлар чиштек. Капитаннар ярышы да искитәрлек күңелле булды.

Бу кичәдән барыбыз да канәгать калдык: дуслык җиңде!

**Галия МӘҖИТОВА,**
“Тукай якташы”
журналистлар клубы

# Республиканская научно-практическая конференция

***23 апреля в нашей школе состоится научно-практическая конференция «Экологическая безопасность современных социально - экономических систем в ракурсе Хартии Земли».***

Хартия Земли — международная декларация основополагающих принципов и ценностей для создания справедливого, устойчивого и мирного глобального общества в XXI веке.

Она призывает человечество установить всеобщее сотрудничество в критический момент нашей истории. Этическое видение Хартии Земли провозглашает, что защита окружающей среды, прав человека, равного человеческого развития и мира взаимозависимы и неразделимы.

Работа конференции будет вестись в семи секциях.

Экологическая безопасность является неотъемлемой частью национальной безопасности Республики Татарстан. Однако состояние экологической безопасности Республики Татарстан вызывает тревогу, так как здоровье людей из-за прошлого и продолжающегося загрязнения находится под угрозой, появляются новые виды загрязнения.

Экологическая ситуация в регионе становится препятствием на пути устойчивого социально-экономического развития, ведет к ограничениям в размещении производств и инфраструктуры, потере конкурентоспособности продукции, росту социальной напряженности, усилению негативной роли экологического фактора в состоянии здоровья населения, сокращению продолжительности жизни.



Общероссийская общественная организация "Центр экологической политики и культуры" является представителем Международной Инициативы Хартии Земли в России.

Она была создана 2007 года. Региональные отделения в 60 субъектах Российской Федерации.

27 апреля 2001 года Госсовет Республики Татарстан принял постановление, согласно которому Татарстан стал первым в мире регионом практического применения Хартии Земли.

*Для участия в конференции необходимо отправить заявку и ранее нигде не опубликованную исследовательскую работу на электронный адрес* ***s2.ars@tatar.ru***

**Редактор** учитель татарского языка и литературы Ибраева Р.Х.
***Ответственный секретарь*** Рузаль Шарипов
***Фотокорреспондент*** Диана Галимова
***Корректор*** Данил Степанов
***Редколлегия*** Алия Хабирова
Гузель Насибуллина
***Адрес:*** ул. Мостовая, дом 15
***Сайт школы*** https://edu.tatar.ru/arsk/sch2